КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 4 декабрь г.Казань № 1043

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгариф өлкәсендә грантлар турында» 2021 ел, 13 август, 708 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгариф өлкәсендә грантлар турында» 2021 ел, 13 август, 708 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 15 ноябрь, 1078 нче; 2022 ел, 29 июнь, 613 нче; 2022 ел, 2 сентябрь, 956 нчы; 2023 ел, 3 февраль, 92 нче; 2023 ел, 24 апрель, 520 нче; 2023 ел, 28 август, 1033 нче; 2023 ел, 25 сентябрь, 1184 нче; 2024 ел, 2 декабрь, 1087 нче; 2025 ел, 26 март, 173 нче; 2025 ел, 29 сентябрь, 777 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гомуми белем бирү оешмасында предметларны укытуны камилләштерү буенча «Безнең яңа укытучы» проектын гамәлгә ашыруга.»;

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гомуми белем бирү оешмасында предметларны укытуны камилләштерү буенча «Безнең яңа укытучы» проектын гамәлгә ашыруга грант бирү турындагы нигезләмәне.»;

әлеге карарга «Гомуми белем бирү оешмасында предметларны укытуны камилләштерү буенча «Безнең яңа укытучы» проектын гамәлгә ашыруга грант бирү турындагы нигезләмәне (карарга теркәлә) өстәргә;

әлеге карар белән расланган «Безнең яңа укытучы» гранты турындагы нигезләмәнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Нигезләмә 2023, 2024 елларда үткәрелгән сайлап алулар нәтиҗәләре буенча «Безнең яңа укытучы» грантын (алга таба – грант) бирү максатларын, шартларын һәм механизмын билгели.».

2. Бу карарның гамәле 2025 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 13 август, 708 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 4 декабрь, 1043 нче
карары редакциясендә)

«Гомуми белем бирү оешмасында предметларны укытуны камилләштерү буенча «Безнең яңа укытучы» проектын гамәлгә ашыруга грант бирү турында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә «Гомуми белем бирү оешмасында предметларны укытуны камилләштерү буенча «Безнең яңа укытучы» проектын гамәлгә ашыруга грант (алга таба – грант) бирү максатларын, шартларын һәм механизмын билгели.

2. Грантлар бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Нигезләмә буенча грантлар бирү максатына бюджет акчасын алучы буларак Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге Нигезләмәдә аннан файдалану максатларында түбәндәге терминнар кулланыла:

грант алырга теләүче – Татарстан Республикасы территориясендә яшәгән, грант алу өчен заявка (алга таба – заявка) бирү вакытына 35 яше тулмаган, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары гамәлгә ашырыла торган муниципаль гомуми белем бирү оешмасында, дәүләт белем бирү оешмасында белгечлек буенча иң күбе биш ел педагогик эшчәнлек стажы булган һәм төп эш урыны буенча «укытучы» төп вазыйфасын биләгән Россия Федерациясе гражданы;

индивидуаль проект – грант алырга теләүче тарафыннан әзерләнгән, гомуми белем бирү оешмасында грант алырга теләүче тарафыннан укыту предметын яки предмет өлкәсен укыту методикасын, укыту практикасын һәм (яки) инновацион укыту методикаларын куллануны камилләштерүгә юнәлдерелгән укыту-методика проекты;

белем бирү оешмасы – башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары гамәлгә ашырыла торган муниципаль гомуми белем бирү оешмасы, дәүләт белем бирү оешмасы;

грант алучы – конкурс нигезендә сайлап алу (алга таба – сайлап алу) йомгаклары буенча грант бирү турында карар кабул ителгән грант алырга теләүче.

4. Ел саен иң күбе 500 грант бирелә.

Грант аны бирү турында карар кабул ителгән елдан соң килә торган елның 31 маена кадәр грант бирелгән елның 1 сентябреннән алып тугыз ай дәвамында ай

саен 10,0 мең сум күләмендә грант бирү турында килешүдә (алга таба – Килешү) билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда бирелә.

5. Грант бирүнең максаты – Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан белем бирү оешмаларында эшләүче, белем бирү оешмасында предметлар укытуны камилләштерү буенча индивидуаль проект гамәлгә ашыручы укытучыларны стимуллау һәм аларга ярдәм күрсәтү.

6. Грант бирү шартлары:

сайлап алуда җиңү;

заявка бирү датасына югары белем бирү буенча әзерлек юнәлешләренең һәм «Мәгариф һәм педагогика фәннәре» урта һөнәри белем бирү белгечлекләренең эреләтелгән төркемнәре кысаларында яки укытыла торган предметка туры килә торган өлкәдә югары белеме яки урта һөнәри белеме яисә белем бирү оешмасы эшчәнлеге юнәлеше буенча югары белеме яки урта һөнәри белеме һәм өстәмә һөнәри белеме булу;

төп эш урынында «укытучы» төп вазыйфасы буенча хезмәт эшчәнлеген кимендә бер тариф ставкасы күләмендә гамәлгә ашыру;

грант алырга теләүченең урта һөнәри һәм (яки) югары белем турындагы һәм (яки) квалификация турындагы документның белем бирү оешмасында педагогик эшчәнлек юнәлешенә һәм укытыла торган укыту предметына туры килүе;

грант алырга теләүченең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентларны түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмавы;

грант алырга теләүче «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

грант алырга теләүче гомуми белем бирү оешмасында предметлар укытуны камилләштерү буенча «Безнең яңа укытучы» проектын гамлгә ашыруга ике тапкырдан артык грант алучы булып тормый.

Сайлап алуда «Безнең яңа укытучы» грантын алучыларга катнашырга рөхсәт ителми.

7. Грант бирү нәтиҗәсе – грант алучы тарафыннан грант бирелгән елның 1 сентябреннән алып грант бирү елыннан соң килә торган елның 31 маена кадәр индивидуаль проектны гамәлгә ашыру.

Грант бирү нәтиҗәсе грант бирү елыннан соң килә торган елның 31 маеннан да соңга калмыйча ирешелергә тиеш.

8. Сайлап алу грант алуга конкурс комиссиясе (алга таба – конкурс комиссиясе) тарафыннан башкарыла. Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми санынннан кимендә яртысы катнашса, хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе карары конкурс комиссиясе әгъзаларының күпчелеге аның өчен тавыш биргән һәм шул ук вакытта утырышта конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санынннан кимендә 50 проценты катнашкан очракта кабул ителгән дип санала.

Тавышлар тигез булганда конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора. Конкурс комиссиясе карары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

9. Конкурс комиссиясе составы, сайлап алуны үткәрү тәртибе, сайлап алу критерийлары, шул исәптән индивидуаль проектны бәяләү критерийлары, заявкаларны кабул итү сроклары һәм сайлап алуны уздыру сроклары, заявкалар кабул

итүне һәм теркәүне гамәлгә ашыручы оператор (алга таба – оператор) турында белешмәләр, грант алырга теләүченең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык формасы, Министрлык белән грант алучы арасында килешү формасы Министрлыкның сайлап алу турындагы боерыгы белән раслана.

10. Министрлык «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында (алга таба – рәсми сайт) түбәндәгеләрне бастырып чыгаруны тәэмин итә:

заявкалар кабул итеәлә башлау датасына кадәр 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, заявкалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы, оператор турында белешмә, заявка составында тапшырыла торган документлар исемлеге белән заявка формасы, заявкалар бирү адресы һәм ысулы, шулай ук рәсми сайтта урнаштырылган сайлап алу турындагы боерыкка сылтама бирелергә тиешле сайлап алуны үткәрү турында белдерү;

заявкалар кабул итеәлә башлау датасына кадәр 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, сайлап алу турында боерык;

заявкалар кабул итүне һәм теркәүне гамәлгә ашыручы оператор турында мәгълүмат, аның урнашу урыны турында белешмәләр, электрон почта адресы, оператор вәкиленең элемтәгә керү өчен телефон номеры;

конкурс комиссиясе беркетмәсе нигезендә ул расланган көннән алып өч эш көне эчендә Министрлыкның грант бирү турында яисә грант бирүдән баш тарту турында боерыгы.

11. Заявкаларны кабул итү һәм теркәү өчен Министрлык гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла торган оешмалар арасыннан операторны билгели. Министрлык карары буенча тиешле техник мөмкинлекләр булганда заявкалар бирү, Россия Федерациясе законнары (шул исәптән шәхси мәгълүматларны саклау өлкәсендә) таләпләрен үтәп, мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып оештырылырга мөмкин.

12. Сайлап алуда катнашу өчен грант алырга теләүчеләр операторга сайлап алу турында боерык белән расланган форма буенча заявка һәм аның составында түбәндәге документларны тапшыра:

сайлап алу турында боерык белән расланган форма буенча индивидуаль проект;

грант алырга теләүченең сайлап алу турында боерык белән расланган форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы;

грант алырга теләүченең паспорт күчермәсе;

белем бирү оешмасы җитәкчесе яки белем бирү оешмасының башка вәкаләтле заты тарафыннан таныкланган белем һәм (яки) квалификация турында диплом күчермәсе;

грант алырга теләүченең эш урыны буенча таныкланган хезмәт кенәгәсе яки тиешле рәвештә таныкланган электрон хезмәт кенәгәсе күчермәсе;

кәгазьдә һәм (яисә) электрон мәгълүмат саклагычта грант алырга теләүченең һөнәри казанышлары турында мәгълүмат бирелгән, белем бирү оешмасының җитәкчесе яки башка вәкаләтле заты тарафыннан таныкланган белешмә кәгазе (раслый торган документларны теркәп);

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият җыемнары, пенялар, штрафлар,

процентлар буенча үтәлмәгән йөкләмәләр булмау турында белешмә кәгазе. Белешмә кәгазе грант алырга теләүче тарафыннан заявка бирү датасына кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча алынырга тиеш.

Сайлап алуга тапшырылган документлар һәм материаллар кире кайтарылмый.

Грант алырга теләүче заявка составында тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җавап бирә.

13. Операторга кергән заявка һәм аның составында бирелгән документлар урнашу урыны буенча операторга алар кергән датадан алып бер эш көне эчендә теркәлә. Заявка почта аша җибәрелгән очракта, заявка оператор тарафыннан почта бүлегендә алынган көннән алып бер эш көне эчендә теркәлә. Заявка электрон рәвештә бирелгән очракта, оператор заявканы операторның электрон адресына кергән көннән бер эш көне эчендә терки.

Грант алырга теләүчене әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы җиденче, сигезенче абзацларында билгеләнгән шартларга туры килү-килмәүгә тикшерү оператор тарафыннан заявка кергән көннән алып бер эш көне эчендә грант алырга теләүче тарафыннан тапшырылганраслаучы документлар, шулай ук ачык мәгълүмат чыганаклары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Теркәлгән заявкалар оператор тарафыннан конкурс комиссиясенә Министрлык боерыгы белән расланган заявкаларны кабул итү тәмамланган көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

14. Әлеге Тәртипнең 16 пунктында билгеләнгән заявкаларны карау һәм сайлап алу конкурс комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла. Конкурс комиссиясе заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган көннән алып 15 эш көне эчендә әлеге Нигезләмәнең 12 пункты нигезендә тапшырылган заявкаларны, документларны карап тикшерә һәм сайлап алуны үткәрә.

15. Грант алырга теләүчегә сайлап алуда катнашудан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

заявканы һәм (яисә) документларны тапшырмау (тулы булмаган комплект тапшыру) яисә алар әлеге Нигезләмә таләпләренә туры килмәү;

бирелгән мәгълүмат дөрес булмау;

заявканы һәм (яисә) документларны заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган датадан соң тапшыру.

Грант алырга теләүчегә сайлап алуда катнашудан баш тартылган очракта, оператор әлеге Нигезләмәнең 14 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә грант алырга теләүчегә заявкада күрсәтелгән электрон почта адресына бу хакта бакш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, хәбәрнамә җибәрә.

16. Сайлап алу түбәндәге этапларны үз эченә ала:

норматив-хокукый, укыту-методика һәм предмет белемнәре дәрәҗәсен билгеләүгә юнәлдерелгән тест узу;

профессиональ-психологик әңгәмә узу;

сайлап алу турында боерык белән расланган бәяләү критерийлары нигезендә индивидуаль проектны бәяләү.

17. Әлеге Тәртипнең 14 пунктында күрсәтелгән срок эчендә, әмма сайлап алу

тәмамланган датадан өч эш көненнән дә соңга калмыйча, конкурс комиссиясе тарафыннан грант алырга теләүчеләрнең сайлап алу йомгаклары буенча җыелган баллар кимү тәртибендә рейтинглы исемлеге төзелә һәм конкурс комиссиясе беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Сайлап алу йомгаклары буенча иң күп балл җыйган, рейтинглы исемлектә 1 нче урыннан 500 нче урынны алган грант алырга теләүчеләр сайлап алуда җиңүчеләр дип таныла.

Әгәр грант алырга теләүчеләр тарафыннан бер үк күләмдә балл җыелган булса, алар рейтинглы исемлектә заявка бирү датасы һәм вакыты буенча урнаштырыла.

Рейтинглы исемлек конкурс комиссиясе беркетмәсенә һәм аның аерылгысыз бер өлеше булып тора.

Министрлык конкурс комиссиясе беркетмәсе нигезендә грант бирү турында йә грант бирүдән баш тарту турында карар кабул итә, ул карар кабул ителгән датадан алып өч эш көне эчендә Министрлыкның грант бирү турында боерыгы белән раслана.

Грант алучыга грант бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

грант алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

грант алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү.

18. Грант, Министрлык тарафыннан грант бирү турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, сайлап алу турында боерык белән расланган форма буенча Министрлык белән грант алучы арасында төзелә торган килешү нигезендә бирелә.

19. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

грант бирү максатлары;

грант күләме;

грантны күчерү сроклары һәм тәртибе;

индивидуаль проектны гамәлгә ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе;

Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан грант алучының грант бирү шартларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы;

грант түләүне туктату очраклары һәм тәртибе;

грантны кире кайтару очраклары һәм тәртибе;

грантны мәҗбүри түләтү буенча чаралар кабул итү сроклары;

грант алучының әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында билгеләнгән грант бирү шартларын үтәү буенча йөкләмәләре;

грант бирү шартларын һәм тәртибен бозган өчен җаваплылык;

грант алучының, әлеге Нигезләмәнең 4 пунктындагы икенче абзацында билгеләнгән грант бирү чорында белем бирү оешмасы белән хезмәт шартнамәсе өзелгән очракта, хезмәт мөнәсәбәтләре туктатылган көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка хәбәр итү йөкләмәсе.

Килешүдә шулай ук грант алучының белем бирү оешмасында «укытучы» төп вазыйфасы буенча индивидуаль проектны гамәлгә ашыру срогы дәвамында хезмәт

педагогик эшчәнлеген гамәлгә ашыру йөкләмәсе дә карала. Грант алучының индивидуаль проектны гамәлгә ашыру срогы дәвамында башка белем бирү оешмасына эшкә урнашу бер муниципаль район, шәһәр округы чикләрендә кадрлар кытлыгын бетерү кирәк булган очракта рөхсәт ителә.

20. Грант түләү грант алучы Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына чакырылган очракта туктатыла, ә элек түләнгән грант суммасы кире кайтарылмый.

Индивидуаль проектны гамәлгә ашыру срогы чыкканга кадәр, белем бирү оешмасы белән хезмәт шартнамәсен өзелгәндә грант түләү, әлеге Нигезләмәнең 19 пунктындагы унөченче абзацында билгеләнгән очрактан тыш, әлеге шартнамә өзелгән вакыттан туктатыла. Элек түләнгән грант суммасы хезмәт шартнамәсе өзелгәннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча тулы күләмдә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Хәрби хезмәткәр булган ире (хатыны) яшәү урынын алыштыруга бәйле рәвештә, грант алучы тарафыннан индивидуаль проектны гамәлгә ашыру срогы чыкканга кадәр эш бирүче белән хезмәт шартнамәсе өзелгән очракта, әлеге шартнамә өзелгән вакыттан грант түләү туктатыла, ә элек түләнгән грант суммасы кире кайтарылмый.

Белем бирү оешмасы бетерелүгә бәйле рәвештә, грант алучы тарафыннан белем бирү оешмасы белән хезмәт шартнамәсе өзелгән очракта, элек түләнгән грант суммасы кире кайтарылмый.

21. Грант алучыларга грант бирү Министрлык тарафыннан Россия кредит оешмаларында ачылган грант алучының шәхси счетларына күчерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

22. Грант алучылар Министрлыкка Килешүдә билгеләнгән форма буенча һәм срок эчендә, әмма грант бирү елыннан соң килә торган елның 31 маеннан да соңга калмыйча, белем бирү оешмасы белән килештерелгән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап булып торган индивидуаль проектны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

Индивидуаль проектны гамәлгә ашыру турында хисапта түбәндәгеләр күрсәтелә:

индивидуаль проектны гамәлгә ашыру кысаларында гранта алучы тарафыннан үткәрелгән чараларның педагогик әһәмияте;

индивидуаль проектта каралган, ирешү нәтиҗәләре белем бирү оешмасы тарафыннан расланган, максатчан күрсәткечләргә ирешүдән гыйбарәт булган грант алучының педагогик эшчәнлеге нәтиҗәлелеге.

Белем бирү оешмасы тарафыннан грант алучының индивидуаль проектта каралган максатчан күрсәткечләргә ирешү фактын раслау индивидуаль проектны гамәлгә ашыру турындагы хисапның беренче битендә уңъяк югары почмакка «Расланды» грифын кую һәм белем бирү оешмасы җитәкчесе яисә аның вәкаләтле заты имзасын кую юлы белән гамәлгә ашырыла.

Министрлык индивидуаль проектны гамәлгә ашыру турында хисапларны сайлап алу турында боерык белән расланган тәртиптә тикшерә.

Әгәр грант алучы тарафыннан әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән

индивидуаль проектны гамәлгә ашыру турында хисап тапшырылмаган булса, грант әлеге Нигезләмәнең 24 пункты нигезендә кире кайтарылырга тиеш.

23. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары грант алучылар тарафыннан грантлар бирү шартлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

24. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр йомгаклары буенча әлеге Нигезләмәдә һәм төзелгән килешүдә билгеләнгән грантлар бирү шартлары һәм тәртибе бозылу факты ачыкланган очракта, грант алучы Министрлыкның язма таләпләрен алган көннән 30 календарь көн эчендә алынган акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтаруны гамәлгә ашыра.

Әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты кеременә ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта, алар Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

25. Грантны максатчан куллануны, аны бирү шартлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

___